Важашур авыл җирлеге Советы

# КАРАР

15 июнь 2022ел №16

Важашур авыл Советның аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Важашур авыл Советы карар бирде:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче (биләгән) затлар тарафыннан үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирү хакында» Важашур авыл Советының 2013 елның 24 апрелендәге 10 номерлы карары;

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Важашур Советының 2016 елның 18 апрелендәге 9 номерлы карары;

- Важашур авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Важашур авыл Советының 2021 елның 9 июнендәге 14 номерлы карары;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы П.Л.Иванов